**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы**

К А Р А Р

**№ 11** **Кәрәкәшле ав.** **«27» апрель 2015 ел**

**Ютазы муниципаль районы**
**Кәрәкәшле авыл җирлегенең**
**2014 елның 20 ноябрендәге “Җир**
**салымы турында”гы 21 санлы карарына**
**үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының II өлешнең 31 бүлегенең 387 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең 2014 елның 20 ноябрендәге «Җир салымы турында»гы 21 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 маддәнең 2 пунктның 10 пунктчасына үзгәрешләр кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «муниципаль берәмлекләрнең башкарма хакимият органнары даими (сроксыз) файдалануга рәсмиләштерелгән яки торак төзелеше өчен, гомуми файдаланудагы объектлар астында файдалану өчен милектә булган җир участоклары өлешендә;»

2. Әлеге карарны:

2.1. административ бинаның мәгълүмати стендында урнаштырырга һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга;

2.2. Россия Федерациясе Салым кодексының I өлешенең 5 маддәсенең 3 пунктына ярашлы рәвештә, 2014 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Дәүләтгәрәев